РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Афанасовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423551, Нижнекамский район,
с. Большое Афанасово ул. Молодежная,1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Афанас авыл жирлеге
Советы

423551, Түбән Кама районы,
Олы Афанас авылы, Яшьләр урамы, 1

тел./факс (8555) 44-43-39, электронный адрес: Afanasovskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.afanasovskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.03.2020 ел № 04-09

Афанас авыл җирлеге
Советының 2018 елның
19 декабрендәге 17-34 номерлы
«Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Афанас авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Афанас авыл җирлегенең тиешле санитар, янгынга каршы, эстетик торышын һәм аны алга таба төзекләндерүне тәэмин итү максатларында, Афанас авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Афанас авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 17-34 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяда

2.3-2.7, 2.16-2.18, 2.25, 2.26 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган һәм әлеге статьяда күрсәтелмәгән төшенчәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә

оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган мәгънәләрдә кулланыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Афанас авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

А.А. Мотыйгуллин